ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

КАРАР
17 апрель 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 279

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне расларга (Кушымта).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Биектау муниципаль районы Советының "Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында" 2009 ел, 29 нчы октябрь 308 номерлы карарын;

Биектау муниципаль районы Советының "Бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында" 2013 ел, 21 нче октябрь 288 номерлы карарын.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үзенең законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советы каршындагы бюджет, финанслар һәм икътисади сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль районы Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

Кушымта
Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
17 апрель 2019 ел № 279

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Бюджет процессының хокукый нигезе

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет законнары, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 ел, 28 нче июль 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының башка муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнгән, бюджет хокукый мөнәсәбәтләре субъектлары арасында төзү, карау, раслау, башкару һәм үтәлешен контрольдә тоту вакытында, шулай ук муниципаль алынмалар һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы (алга таба – муниципаль берәмлек) муниципаль бурычы белән идарә иткәндә барлыкка килә торган бюджет хокукый мөнәсәбәтләрен тәртипкә сала.

2. Әлеге Тәртиптә кулланылучы төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән мәгънәдә кулланылалар.

2 статья. Муниципаль берәмлек бюджетының хокукый формасы

1. Муниципаль берәмлек бюджеты (алга таба - бюджет) һәм аның үтәлеше турында хисап Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы карары формасында әзерләнә һәм раслана (алга таба - Совет).

2. Бюджет турында карар билгеләнгән тәртиптә аны имзалаганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3 статья. Россия Федерациясе бюджет классификациясе кулланылышы

1. Бюджет вәкаләтләренә Россия Федерациясе бюджет классификациясенең бюджетка караган өлкәсендә билгеләү, детальләштерү һәм урнаштыру тәртибен ачыклау керә.

2. Бюджет керемнәренең баш бүлүчеләре исемлеге, алар артыннан беркетелә торган район бюджеты төрләре (төрчәләре) район бюджеты турында район Советы карары нигезендә раслана.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) баш администраторлары саналган җирле үзидарә органнары һәм (яки) алар карамагында булган казна учреждениеләре

керемнәр төрләре буенча кече төрләр кодлары исемлеген раслый.

Район бюджет чаралары баш бүлүчеләре исемлеге район бюджеты турында район Советы карары нигезендә чыгымнарның ведомство структурасы составында раслана.

Район бюджеты бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәр һәм төркемчәләр) район бюджеты турында район Советы карары нигезендә чыгымнарның ведомство структурасы составында раслана яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән очраклар нигезендә билгеләнә.

Һәрбер гавами норматив йөкләмәгә, бюджетара трансферга, җирле үзидар органы эшчәнлегенең аерымланган функциясенә (өлкәсенә, юнәлешенә) район бюджеты чыгымнары максатчан статьяларыныж уникаль кодлары билгеләнә.

Район бюджеты чыгымнары масатчан статьялары исемлеге һәм кодлары район бюджеты бюджет исемлеге район бюджетын төзү һәм үтәүне оештыруны тормышка ашыручы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә, башкасы Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән белән билгеләнмәсә.

Максатчан билгеләнешкә ия булган бюджеттан тәкъдим ителә торган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына финанс тәэмин итү тормышка ашырыла торган бюджет чыгымнарының максатчан статьялары исемлеге һәм кодлары күрсәтелгән максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирелә торган район бюджеты бюджет исемлеге район бюджетын төзү һәм үтәүне оештыруны тормышка ашыручы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ачыклана.

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары баш администратолары исемлеге район бюджеты турында район Советы карары нигезендә расланалар.

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары статьялары исемлеге район бюджеты турында район Советы карары нигезендә район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары раслау вакытында расланалар.

4 статья. Бюджет процессы принциплары һәм этаплары

1. Муниципаль берәмлектә бюджет процессы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы принципларына нигезләнә.

2. Бюджет процессының төп этаплары булып торалар:

- бюджет проектын төзү;
- бюджетны карау һәм раслау;
- бюджетны үтәү;
- муниципаль финанс контрольне тормышка ашыру.

5 статья. Бюджет процессы катнашучылары һәм аларның вәкаләтләре

1. Бюджет процессы катнашучылары:

1) Биектау муниципаль районы Башлыгы (алга таба – Башлык);

2) Совет;

3) ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет);

4) районның Финанс-бюджет палатасы;

5) “Биектау муниципаль районы контроль-хисап палатасы” МКУ (алга таба - район контроль-хисап палатасы);

6) бюджет чаралары белән баш бүлүчеләр (баш бүлүчеләр);

7) бюджет керемнәре баш администраторлары (администраторлар);

8) бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлар);

9) бюджет чараларын алучылар.

2. Совет бюджетны һәм аның үтәлеше турында хисапны карый һәм раслый, үзенең утырышларында, комиссия утырышларында, Совет эшче төркеме, Совет тарафыннан уздырыла торган тыңлаулар, депутат соратулары булганда бюджет үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау вакытында контрольне тормышка ашыра, тышкы муниципаль финанс контроле органнарының хокукый статусын формалаштыра һәм билгели, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында” 2011 ел, 7 нче февраль 6-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба - Устав), әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

Советка үзенең компетенциясе чикләрендә, Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бюджет мәсьәләләре буенча, аларның вәкаләтләрен тәэмин итү өчен барлык кирәкле мәгълүмат Башкарма комитетка тәкъдим ителергә тиеш.

3. Башкарма комитет бюджет проектын төзүне тәэмин итә, аны кирәкле документлар һәм материаллар белән раслау өчен Советка кертә, бюджетара трансфертлар тәкъдим итү тәртибен һәм (яки) бүлеп бирү методикасын эшләп чыгара һәм раслый, бюджет үтәлешен һәм бюджет хисабын төзүне тәэмин итә, бюджет үтәлеше турында хисапны раслау өчен Советка тәкъдим итә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Тәртип һәм (яки) алар нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

4. Районның финанс-бюджет палатасы бюджет проектын төзи, аны кирәкле документлар һәм материаллар белән Советка кертү өчен тәкъдим итә, бюджет үтәлешен оештыра, бюджет хисабын төзү тәртибен билгели, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Тәртип һәм (яки) алар нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актлар нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен тормышка ашыра.

5. Районның контроль-хисап палатасы түбәндәге бюджет вәкаләтләрен тормышка ашыра:

җирле бюджет үтәлеше буенча контроль;

җирле бюджет проектлары экспертизасы;

җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

җирле бюджет чараларын куллану, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән башка төр чыганаклардан җирле бюджет ала торган чаралар контролен законлы, результатив (нәтиҗәле һәм сакчыл) оештыру һәм тормышка ашыру;

муниципаль милектә булган милек белән билгеләнгән идарә итү һәм эш йөртү тәртибен, шул исәптән муниципаль берәмлекнеке булган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм шәхси чаралар белән саклана торганнарын да контрольдә тоту;

тәкъдим ителгән салым һәм башка ташламаларның, җирле бюджет чаралары хисабына бюджет кредитлары нәтиҗәлелегенә бәя бирү, шулай ук муниципаль гарантияләр һәм поручительство тәкъдим итүнең законлылыгына бәя бирү яки муниципаль милектә булган җирле бюджет һәм милек чаралары хисабына юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр башкара торган килешү буенча җаваплылыкны башка ысуллар белән башкаруны тәэмин итү;

муниципаль хокукый акт проектларын муниципаль берәмлек чыгым йөкләмәләренә кагылган өлкәсендә, шулай ук муниципаль программаларны финанс-икътисад экспертизасы (финанс-икътисад нигезләрнең дәлилләрен дә кертеп);

муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерергә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү;

җирле бюджет үтәлү процессы, уздырылган контроль һәм эксперт-аналитик чаралары нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм әлеге мәгълүматны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле оранына һәм муниципаль берәмлекнең башлыгына тәкъдим итү;

ришвәткә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләре кысаларында катнашу;

Биектау муниципаль районы составына керүче җирлек бюджетларына күчкән Биектау муниципаль районы бюджеты чараларын куллануның законлы, результатив (нәтиҗәле һәм сакчыл) контроле;

тышкы муниципаль финанс контроль өлкәсендә федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының уставы һәм норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләр.

Әлеге пункт нигезендә каралган районның контроль-хисап палатасының бюджет вәкаләтләре "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында" 2011 ел, 7 нче февраль 6-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән нигезләмәләрне тотып тормышка ашырыла.

6. Бюджет чаралары баш бүлүчеләр:

бюджет чараларын куллануның бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм аның өчен расланган бюджет ассигнованиеләре нигезендә нәтиҗәлелеген, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;

аңа ведомство карамагында булган бюджет чараларын бүлүчеләр һәм алучылар исемлеген формалаштыра;

аның өчен расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет

ассигнованиеләре чикләрендә үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

билгеле бюджет чыгымнарын планлаштыруны тормышка ашыра, бюджет ассигнованиеләренең нигезләрен төзи;

бюджет исемлеген төзи, раслый һәм алып бара, ведомство карамагында булган бюджет чараларын бүлүчеләр һәм алучылар буенча бюджет ассигнацияләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын бүлеп бирә һәм бюджетның билгеле бүлеген үти;

бюджет йөкләмәләре лимитларын форалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

җыелма бюджет исемлеген формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

казна учреждениеләре саналган ведомство карамагында булган бюджет чараларын алучыларның бюджет сметасын раслау тәртибен ачыклый;

муниципаль йөкләмәне формалаштыра һәм раслый;

максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар алучыларның, шулай ук әлеге Кодекс белән билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрне, аларны тәкъдим иткәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне тотуны тәэмин итә;

бюджет чараларын баш бүлүче бюджет хисабын формалаштыра;

муниципаль берәмлек исеменнән аның ведомствосы карамагында булган бюджет чараларын алучыларның акча йөкләмәләре буенча җавап бирә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Тәртип һәм (яки) алар нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актлар нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен тормышка ашыра.

түбәндәгеләргә юнәлдерелгән эчке финанс контрольне тормышка ашыра:

Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка төр норматив хокукый актлар, эчке стандартлар һәм процедуралар һәм чыгымнары буенча бюджет үтәлеше процедуралары, дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр хезмәтләр сатып алуга чыгымнарны да кертеп, әлеге бюджет чараларын баш бүлүче һәм аның ведомство карамагында булган бүлүчеләр һәм бюджет чараларын алучылар тарафыннан бюджет хисабын хисабын төзү һәм бухгалтер исәбен алып бару;

бюджет чараларын кулланынуың икътисадилыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар әзерләү һәм оештыру.

7. Бюджет чараларын бүлүче:

билгеле бюджет чыгымнарының планлаштыруны тормышка ашыра;

ведомство карамагында булган бүлеп бирүчеләр һәм (яки) бюджет чараларын алучылар буенча бюджет ассигнацияләрен, бюджет лимитларын бүлеп бирә һәм билгеле бюджет өлешен үти;

бюджет чараларының аның карамагында булган төп бүлеп бирүчесенә бюджет исемлеген формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар алучыларның, шулай ук әлеге Кодекс белән билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен, аларны тәкъдим иткәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне тотуны тәэмин итә;

бюджет чаралары белән билгеле баш бүлүче тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә, аның карамагында булган бюджет чаралары белән баш бүлүче аерым бюджет вәкаләтләрен тормышка ашыра.

8. Бюджет чараларын алучы түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

бюджет сметасын төзи һәм үти;

бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм (яки) бюджет ассигнованиеләренең китереп җиткерелгән чикләрендә үтәлергә тиешле бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яки) үти;

аңа каралган бюджет ассигнованиеләрен куллануның результативлыгын, куллануның максатчан характерын тәэмин итә;

бюджет чараларының билгеле баш бүлүчегә (баш бүлүчегә) бюджет исемлеген үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертү;

бюджет хисабын (бюджет хисабын алып баруны тәэмин итә) алып бара;

бюджет хисабын формалаштыра (бюджет хисабы формалаштыруын тәэмин итә) һәм бюджет чараларының билгеле баш бүлүче (баш бүлүче) бюджет хисабын тәкъдим итә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Тәртип һәм (яки) алар нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

9. Бюджет керемене баш администраторы:

аңа ведомство карамагында булган бюджет керемнәре исемлеген формалаштыра;

уртача сроклы финанс планын һәм (яки) бюджет проектын төзү өчен кирәкле мәгълүматлар тәкъдим итә;

касса планын төзү һәм алып бару өчен мәгълүматлар тәкъдим итә;

бюджет кереме баш администраторының бюджет хисабын формалаштыра һәм тәкъдим итә;

бюджет керемен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджет керемнәре чыганаклары исемлеге нигезендә аның артыннан беркетелгән керем чыганаклары буенча чыганаклар реестрын алып бара;

бюджетка керемнәр керүне фаразлау методикасын, әлеге методикага Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә раслый;

әлеге Кодекс һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар (муниципаль хокукый актлар) нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен тормышка ашыра.

Билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка төр норматив хокукый актлар, эчке стандартлар һәм процедуралар һәм керемнзр буенча бюджет төзү һәм үтәү процедураларын, әлеге бюджет керемнәре баш бүлүчесе һәм аның бюджет керемнәре ведомство карамагында булган бүлүчеләр тарафыннан бюджет хисабын хисабын төзү һәм бухгалтер исәбен алып баруны тотуга юнәлдерелгән эчке финанс контролен тормышка ашыра.

10. Бюджет кытлыгы чыганакларының баш администраторы:

үзенең ведомство карамагында булган админситраторларның бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исемлеген формалаштыра;

бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне планлаштыруны (фаразлау) тормышка ашыра;

аның карамагына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын каплау өчен бирелгән ассигнованиеләрне куллануның адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;

бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының ведомство карамагында булган администраторлары буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирә һәм бюджетның билгеле өлешен үти;

бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш админситраторының бюджет хисабын формалаштыра;

бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне фаразлау методикасын, әлеге методикага Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә раслый;

бюджет ассигнованиеләренә дәлилләр төзи.

Билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет законнары, бюджет мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка төр норматив хокукый актлар, эчке стандартлар һәм процедуралар һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча төзү һәм үтәү процедуралары, әлеге бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторлары һәм бюджет кытлыгын финанаслау чыганаклары администраторы тарафыннан бюджет хисабын хисабын төзү һәм бухгалтер исәбен алып баруны тотуга юнәлдерелгән эчке финанс контролен тормышка ашыра.

11. Бюджет чараларының баш бүлүчесенең (баш бүлүче), бюджет керемнәренең баш администраторының (администратор), эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудитын тормышка ашыру буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының (администратор) бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнәләр.

6 статья. Бюджет керемнәре

1. Бюджет керемнәре Россия Федерациясе Бюджет законнары, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары һәм башка мәҗбүри түләүләр турында законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы бюджет кодексы һәм салымнар һәм җыемнар турында Татарстан Республикасы законнары, Советның салымнар һәм җыемнар турында норматив-хокукый актлары нигезендә формалашалар.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы, җирле бюджет керемнәре үзгәрүенә китерүче, киләсе финанс елында һәм планлы периодта үз көченә керүче җирле салымнар турында карарларга үзгәрешләр кертү турында Совет карарлары бюджет турында киләсе финанс елына һәм планлы периодка карар проектын Советка керткәнче 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

7 статья. Бюджет чыгымнары

1. Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет чыгымнарын формалаштыру федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә чикләүгә бәйле һәм Россия

Федерациясе законнары, халыкара һәм башка шартнамәләр һәм килешүләр буенча чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) тиешле бюджет акчалары исәбеннән үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

8 статья. Резерв фонды

1. Бюджетның чыгымнар өлешендә Башкарма комитеты резерв фондын булдыру күз алдында тотыла.

2. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының чыгымнар өлешендә закон чыгару (вәкиллекле) органнарның һәм закон чыгару (вәкиллекле) органнарының депутатларының резерв фондларын булдыру тыела.

3. Башкарма комитетның резерв фонды күләме билгеле бюджетлар турында законнар (карарлар) белән билгеләнә һәм күрсәтелгән закон белән расланган чыгымнарның гомуми күләменнән 3 процентта да артмаска тиеш.

4. Башкарма комитетның резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә, шул исәптән һәлакәт-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казаларның, башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка гамәлләрне уздыруга, шулай ук әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән тәртиптә каралган башка чараларга җибәрелә.

5. Башкарма комитет резерв фондының җирле бюджет составында каралган бюджет ассигнованиеләре Башкарма комитет карары буенча файдаланыла.

6. Башкарма комитет резерв фондының җирле бюджет составында каралган бюджет ассигнованиеләрен файдалану тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

7. Башкарма комитетның резерв фонды бюджет ассигнованиеләрен файдалану турындагы хисап билгеле бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапка кушып бирелә.

9 статья. Бюджетта каралмаган чыгымнарны гамәлгә ашыру

1. Әгәр чыгым йөкләмәләренең гамәлдәге төрләре буенча чыгым йөкләмәләрен арттыруны яисә аны кабул иткәнче бер генә гавами-хокукый берәмлек белән үтәлмәгән чыгым йөкләмәләренең яңа төрләрен гамәлгә кертүне күз алдында тоткан муниципаль норматив хокукый акт кабул ителсә, күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актта чыгым йөкләмәләренең яңа төрләре чыганакларын һәм аларны үтәү тәртибен, шул исәптән кирәк очракта чыгым йөкләмәләренең яңа төрләренә финанс ресурсларын Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларына тапшыру тәртибен билгели торган нормалар булырга тиеш.

2. Чыгым йөкләмәләренең яңа төрләрен кабул итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү яисә чыгым йөкләмәләренең гамәлдәге төрләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыру, бюджет турындагы карарга тиешле бюджет ассигнованиеләрен кертү шарты белән, чираттагы финанс елы башыннан яисә бюджетка өстәмә кертемнәрнең тиешле чыганаклары булганда һәм бюджет чыгымнарының аерым статьялары буенча бюджет ассигнованиеләре кыскартылганда гына, бюджет турындагы Совет карарына тиешле үзгәрешләр керткәннән соң агымдагы финанс елында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

10 статья. Чыгым йөкләмәләре

1. Муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре түбәндәгеләр нәтиҗәсендә барлыкка килә:

җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм федераль законнар нигезендә жирле үзидарә органнары хәл итәргә хокуклы бүтән мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул итү, шулай ук шушы мәсьәләләр буенча муниципаль берәмлек тарафыннан (муниципаль берәмлек исеменнән) шартнамәләр (килешүләр) төзү;

үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен жирле үзидарә органнары башкарганда муниципаль хокукый актлар кабул итү;

муниципаль казна учреждениеләре тарафыннан муниципаль берәмлек исеменнән шартнамәләр (килешүләр) төзү.

2. Муниципаль берәмлекнең әлеге статьяның 1 пунктында 1,3 бүлекләрендә күрсәтелгән чыгым йөкләмәләре жирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм үз керемнәре, тиешле жирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән үтәлә.

3. Муниципаль берәмлекнең әлеге статьяның 1 пункты 2 бүлегендә күрсәтелгән чыгым йөкләмәләре федераль законнар (Татарстан Республикасы законнары) нигезендә жирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста каралган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан жирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбенә һәм кысаларында үтәлә.

Әгәр тиешле субвенцияләрне исәпләп чыгару методикаларында файдаланыла торган нормативлар муниципаль берәмлектә арттырылган булса, муниципаль берәмлекнең күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен тулысынча үтәү өчен кирәкле өстәмә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү үз керемнәре һәм жирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исәбенә башкарыла.

3.1. Муниципаль районның жирле үзидарә органнары һәм авыл жирлекләренең жирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр нигезендә авыл жирлекләренең жирле үзидарә органнарына жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен муниципаль районнарның жирле үзидарә органнары гамәлгә ашыруга яисә муниципаль районның жирле үзидарә органнары һәм авыл жирлекләре арасында төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль районның жирле үзидарә органнарына жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен авыл жирлекләренең жирле үзидарә органнары гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре әлеге килешүләр нигезендә жирле үзидарә органнарының тиешле муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 31.07.1998 елгы 145-ФЗ Федераль законның (алга таба – РФ БК) 142.4 һәм 142.5 статьяларында каралган тәртиптә бирелә торган тиешле жирле бюджетларның бюджетара трансфертлары исәбеннән һәм чикләрендә үтәлә.

Әгәр муниципаль берәмлектә тиешле бюджетара трансфертларны исәпләү методикаларында кулланыла торган нормативлар артып китсә, муниципаль берәмлекнең күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен тулысынча үтәү өчен кирәкле өстәмә чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү шул муниципаль берәмлекнең үз керемнәре һәм жирле бюджет кытлыгын финанслау чыгымнары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы урындагы затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү күләмнәрен һәм шартларын, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләрне үтәп, мөстәкыйль билгели.

5. Җирле үзидарә органнары федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш, чыгым йөкләмәләрен билгеләргә һәм үтәргә хокуксыз.

Җирле үзидарә органнары башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә карамаган һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән алар компетенциясеннән алынмаган чыгым йөкләмәләрен бары тик үз финанс чаралары булганда гына (бюджетара трансфертлардан гайре) билгеләргә һәм үтәргә хокуклы.

11 статья. Бюджет кытлыгы

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына бюджет кытлыгы әлеге статьяның 2 нче бүлегендә билгеләнгән чикләүләрне үтәгән килеш, бюджет турында Совет карары белән билгеләнә.

2. Бюджет кытлыгы бюджет керемнәренең, кире кайтарып бирелми торган акчаларның расланган күләмен исәпкә алмыйча, расланган еллык гомуми күләменең 10 процентыннан артмаска тиеш.

Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлегенә карата РФ БК 136 статьясы 4 пункты белән каралган чаралар тормышка ашырылган очракта, бюджет кытлыгы бюджет керемнәренең, кире кайтарып бирелми торган акчаларның һәм (яки) өстәмә норматив акча күчерүләр буенча салым керемнәреннән акча керүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, расланган еллык гомуми күләменең 5 процентыннан артмаска тиеш.

Бюджет турында Совет карары белән муниципаль берәмлек милкендәге акцияләрне сатудан һәм капиталында катнашуның бүтән рәвешләреннән керемнәрне җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында раслау һәм (яисә) җирле бюджет акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларның кимү очрагында җирле бюджет кытлыгы күрсәтелгән керемнәр суммасы һәм җирле бюджет акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларның кимүе чикләрендә әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләрдән артыграк булырга мөмкин.

3. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап күрсәткечләре буенча барлыкка килгән бюджет кытлыгы әлеге статьяның 2 бүлегендә билгеләнгән чикләүләргә туры килергә тиеш.

Киләсе финанс елыныд 1 нче гыйнварына кадәр бюджет турында карар расланган очракта бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында Россия Федерациясе бюджет системасы башка бюджетлары тарафыннан бюджетка бирелгән алынган һәм түләнгән бюджет кредитлары аермасы булганда бюджет кытлыгы әлеге статьяның 2 пункты белән билгеләнгән чикләүләрдән артыграк булырга мөмкин.

12 статья. Бюджет кредитлары

1. Бюджет кредитлары бюджет чаралары хисабына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Совет карары белән билгеләнгән тәртиптә, шулай ук бюджет турында Совет карары белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм шартларында Россия Федерациясе башка бюджет системасы бюджетларына, юридик затларга тәкъдим ителәләр.

13 статья. Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары

1. Бюджет кытлыгын эчке финанслау чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

1) номиналь хакы Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән муниципаль кыймәтле кәгазьләрне урнаштырудан килгән акчалар белән аларны түләүгә юнәлдерелгән акчалар арасындагы аерма;

2) кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган һәм түләнгән кредитлар арасындагы аерма;

3) бюджетка Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган һәм түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

4) максатчан чит ил кредитларын (үзара бурычлар алуларны) файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында бирелгән алынган һәм түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

5) тиешле финанс елы дәвамында бюджет акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү;

6) бюджет кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары.

2. Бюджет кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

1) муниципаль берәмлек милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан килгән акчалар;

2) бюджет акчалары буенча курс аермасы;

3) муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләрне үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме йә гарантка бенефициарның принципалга карата таләп хокукларына юл кую шарты белән;

4) муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләрне үтәүгә чит ил максатчан кредитларын (үзара бурыч алулар) кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан җибәрелә торган акчалар күләме;

5) Россия Федерациясе валютасындагы бүтән бурыч йөкләмәләрен түләүгә җибәрелә торган акчалар күләме;

6) бюджеттан юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар белән бюджеттан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма;

7) бюджеттан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар

белән бюджеттан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма.

8) җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр башкарганда, җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счеттан күчерелгән акчалар һәм җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетка күчерелгән акчалар арасындагы аерма.

Җирле бюджетның агымдагы финанс елы башына калган акчалары хисап финанс елында кулланылмаган муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре агымдагы финанс елында муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелләр, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплау өчен һәм товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә, юридик затларга субсидияләр бирү өчен җирле бюджет турында Совет карарында билгеләнгән очракларда, күрсәтелгән максатларда хисап финанс елында түләнергә тиешле субсидия алучыларның акча йөкләмәләре күрсәтелгән финанс тәэмин итү чыганагы булган субсидияләр бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелергә мөмкин.

Җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр составына гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси счетлары Федераль казначылыкның территориаль органыныңа яки муниципаль берәмлекнең финанс органында ачылган оешмаларның акчаларын җәлеп итү һәм кире кайтару керә.

14 статья. Муниципаль бурыч алулар һәм муниципаль бурыч

1. Муниципаль бурыч алулар дигәндә муниципаль берәмлек исеменнән Россия Федерациясе валютасында эчке базарга урнаштырыла торган кыйммәтле кәгазьләр чыгару юлы белән башкарыла торган муниципаль бурыч алулар һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Кодекс нигезләмәләре нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән һәм шулар буенча муниципаль бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар аңлашыла.

Бурыч алулар Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясеннән читтә хисаплашулар рөхсәт ителми.

Муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашыру хокукына Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Устав нигезендә Башкарма комитет ия була.

Агымдагы финанс елында бурыч алуларның иң чик күләме РФ БК 104 һәм 104.1 статьяларын истә тотып агымдагы финанс елында бюджет кытлыгын һәм (яки) бурый йөкләмәләрен бетерү өчен финанслауга юнәлдерелгән суммадан артырга тиеш түгел.

2. Муниципаль бурыч – муниципаль бурыч алулардан, өченче затларның

йөкләмәләре бенча гарантияләрдән, бурый йөкләмәләре төрләре нигезендәге башка йөкләмәләрдән килеп чыга торган Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән Биектау муниципаль район тарафыннан үзенә алынган йөкләмәләрне әйтәләр.

3. Муниципаль бурыч структурасы Россия Федерациясе бурыч йөкләмәләренең Бюджет кодексында һәм әлеге статьяда билгеләнгән төрләре буенча муниципаль бурыч йөкләмәләре төркемләвеннән гыйбарәт була.

Бурыч йөкләмәләре түбәндәгеләр буенча бурыч йөкләмәләре рәвешендә булырга мөмкин:

кыйммәтле кәгазьләр (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр);

Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

кредит оешмаларыннан алынган кредитлар;

гарантияләр (муниципаль гарантияләр).

Бурыч йөкләмәләре кыска сроклы (бер елдан ким), урта сроклы (бер елдан биш елга кадәр) һәм озак срокка (биш елдан 10 елга кадәр) булырга мөмкин.

4. Муниципаль бурычның иң чик күләме, кире кайтарылмый торган түләүләрнең һәм (яки) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен түләүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, бюджет керемнәренең гомуми еллык расланган күләменнән артмаска тиеш.

Әлеге Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар үзенә карата гамәлгә ашырыла торган Биектау муниципаль районы өчен, муниципаль бурычның иң чик күләме кире кайтарылмый торган түләүләрне һәм (яки) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча, бюджет керемнәренең гомуми еллык расланган күләменең 50 процентыннан да артмаска тиеш.

Киләсе финанс елының 1 нче гыйнварына кадәр муниципаль бурычның иң чик күләме, әлеге пункт белән билгеләнгән чикләүләрдән, агымдагы елның 1 нче гыйнварына бюджет кредитлары буенча муниципаль бурыч күләме чикләрендә һәм (яки) агымдагы финанс елында җирле бюджетка Россия Федерациясенең башка бюджет системаларыннан җәлеп ителә торган бюджет кредитлары бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында бюджет турында карар расланса артырга мөмкин.

5. Бюджет турында карар белән расланган чираттагы финанс елында һәм план чорында муниципаль бурычны тәэмин итү буенча чыгымнар күләме хисап финанс елында бюджет үтәлеше турында хисап мәгълүматлары буенча бюджет чыгымнары күләменнән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән башкарыла торган чыгымнар күләменнән гайре, 15 проценттан артмаска тиеш.

15 статья. Муниципаль гарантияләр бирү

1. Муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль гарантияләр Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә һәм әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет тарафыннан бирелә, бирелә торган гарантияләрнең гомуми суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында карарда

күрсәтелгән чикләрдә була.

2. Башкарма комитет муниципаль гарантияләрне бирү турында, гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү (өлешчә үтәү) йөзеннән гарант тарафыннан түләнгән суммалар регрессы тәртибендә гарантка түләү буенча принципалның ихтимал киләчәк йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү турында шартнамәләр төзи һәм муниципаль гарантияләр бирә.

Гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү (өлешчә үтәү) йөзеннән гарант тарафыннан түләнгән суммалар регрессы тәртибендә гарантка принципалның түләү тәртибе һәм вакытлары гарант белән принципал арасындагы шартнамә белән билгеләнә. Бу мәсьәләләр буенча яклар килешүе булмаганда, гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү гарант таләбендә күрсәтелгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

Муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләрнең Россия Федерациясе валютасындагы, шулай ук РФ БК 104 статьясындагы 4 пункт нигезендә бирелгән муниципаль гарантияләр чит ил валютасындагы гомуми суммасы бурыч йөкләмәсе төре буларак кертелә.

Муниципаль гарантияне бирү һәм үтәү муниципаль бурыч кенәгәсендә чагылдырылырга тиеш.

Районның Финанс-бюджет палатасы бирелгән гарантияләрнең, принципалның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең үтәлешен, шулай ук бирелгән гарантияләр буенча гарант түләүләрен исәпкә алып бара.

16 статья. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә бирелгән субсидияләрдән кала), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга субсидияләр бирү

1. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә бирелгән субсидияләрдән кала), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр эшләп чыгаручы физик затларга субсидияләр бирү бушлай һәм кайтарып булмый торган нигездә алып бетерелмәгән керемнәре кайтару һәм (яки) чыгымнарны финанс тәэмин итү товарларны җитештерү (урнаштыру) белән бәйле (акцизлы товарлардан, җиңел машина һәм мотоцикллар, Россия Федерациясе территориясендәге виноградтан эшләнгән шәраб продуктларыннан кала), эшләрне башкару, хезмәтләр күрсәтү максатыннан бирелә.

2. Юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә бирелгән субсидияләрдән һәм әлеге статьяның 6-8 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрдән кала), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр эшләп чыгаручы физик затларга субсидияләр бирелә:

1) федераль бюджеттан һәм Россия Федерациясе дәүләт бюджетыннан тыш фондларыннан - федераль бюджет турында федераль законнар, Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары турында федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары яки аларга вәкаләтле дәүләт хакимияте федераль органнары (федераль дәүләт органнары) актлары нигезендә;

2) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлары бюджетыннан – Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы законнары, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлары турында Татарстан Республикасы законнары һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы норматив хокукый актлары яки аларга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары нигезендә;

3) җирле бюджеттан - җирле бюджет турында муниципаль берәмлек Советы карары белән каралган һәм аның нигезендә кабал ителә торган Башкарма комитетның муниципаль хокукый актлары яки вәкаләтле җирле үзидарә органнары актларында каралган очракларда һәм тәртиптә.

3. Юридик затларга (муниципаль учреждениеләрдән кала), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән гомуми таләпләргә туры килергә һәм түбәндәгеләрне ачыкларга тиеш:

1) субсидия алырга хокукы булган юридик затларның (муниципаль учреждениеләрдән кала), шәхси эшмәкәрләрнең, шулай ук товар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларның категорияләрен һәм (яки) сайлау критерияләрен;

2) субсидия бирүнең максатын, шартларын һәм тәртибен;

3) субсидия бирү шартларын бозган очракта тиешле бюджетка аны кайтару тәртибен;

4) субсидия алучылар тарафыннан хисап финанс елында кулланылмаган (субсидия алучыларның акча йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле булган сумма чикләрендә тәкъдим ителгән субсидияләрдән кала, күрсәтелгән субсидияләр финанс тәэмин итү чыганагы булганда) товарлар җитештерү (урнаштыру), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс тәэмин итү максатларында субсидиянең калганын агымдагы финанс елында кайтару очраклары һәм тәртибе;

5) субсидияләр бирүче бюджет чараларын белән баш бүлүчеләр (баш бүлүчеләр) тарафыннан мәҗбүри тикшерү турында, һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан субсидияләр бирүнең шартларын, максатларын һәм субсидияне аларны алучыларга бирү тәртибен тоту.

3.1. Субсидия алучылар тарафыннан аларны биргәндә әлеге статья белән каралган шартларны бозган очракта билгеле чаралар норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән, әлеге статьяның 8 пунктының 4 абзацы һәм 3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә Россия Федерциясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтарып бирелергә тиеш.

4. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне биргән вакытта субсидияләрне бирү турында аларны бирүне җайга салучы шартнамәләр (килешүләр) һәм (яки) норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар, әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатыннан төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертелү аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып субсидия алучыларның ризалыгы һәм субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатыннан төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) булган затларның (унитар муниципаль предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләре һәм устав (склад) капиталларында җәмәгать-хокукый берләшмәләре катнашкан җәмгыятьләрдән, шулай ук әлеге

ширкәтләр катнашында һәм аларның устав (склад) капиталларында булган җәмгыятьләр булган коммерцияле оешмалардан кала) субсидияләрне биргән бюджет чараларын баш бүлүче (баш бүлүче) белән тормышка ашыру, дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан аларга субсидияләр бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибен тоту буенча тикшерүләр.

4.1. Юридик затларга әлеге статья нигезендә субсидияләр бирү вакытында әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән аларны бирүнең товарлар җитештерү (урнаштыру), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс тәэмин итү турында шартнамәләргә (килешүләргә) һәм (яки) аларны бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга кертелгән мәҗбүри шарты булып алынган чараларга чит ил валютасын алырга тыю, югары технологияле җиһазлар, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләр сатып алулар (тәэмин итү) вакытында Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә тормышка ашырыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне тәэмин итүне җайга салучы норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге чаралар башка төр операцияләр максатларына ирешү белән бәйле тыюлар санала.

5. Әлеге статья белән каралган субсидияләр федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан муниципаль-шәхси партнерлык турында Россия Федерациясе законнары, концессион килешүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр, концессион килешүләр турында килешүләр белән каралган шартларда һәм сроклар нигезендә тәкъдим ителә.

6. Бюджет турындагы карарда Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъекты югары вазыйфаи заты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органы, Башкарма комитет карарлары нигезендә юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән кала), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга грантларны субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күздә тотылырга мөмкин.

Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетлардан күрсәтелгән субсидияләрне бирү тәртибе билгеле рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органнары норматив хокукый актлары, Башкарма комитет муниципаль хокукый актлары нигезендә билгеләнә, әгәр дә әлеге тәртип әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә карарлар белән ачыкланмаса.

7. Бюджет турында законда (карарда) федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан юридик затларга тәкъдим ителүче бюджет ассигнованиеләре бирү мөмкин булса, аларның 100 процент (өлеш) акцияләре Россия Федерациясенә, Татарстан Республикасына, муниципаль берәмлеккә караган, күрсәтелгән юридик затларның милкендә булган капиталь төзелеш объектларына капиталь акча салулар һәм (яки) Россия Федерациясе законнары нигезендә алар тарафыннан күчемсез милек объектларын алга таба андый юридик затларның устав капиталларын арттыру белән алу.

Әлеге пунктның беренче абзацы белән каралган федераль бюджеттан,

Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карар Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органнары норматив хокукый актлары, Башкарма комитет муниципаль хокукый актлары формасында алар билгеләгән тәртиптә бирелә.

Әлеге пунктның беренче абзацы белән күздә тотылган субсидияләрне бирү бюджет чараларын алучылар белән субсидия бирүчеләр һәм субсидия бирелә торган юридик зат арасында шартнамәләр (килешүләр) нигезендә тормышка ашырыла. Күрсәтелгән шартнамәгә (килешүгә) әлеге пунктның беренче абзацы белән күздә тотылган субсидия бирелә торган юридик затның вазыйфаларын ачыклаучы нигезләмәләр кертелергә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алынган чаралар хисабына сатып алуларны тормышка ашырырга, шулай ук хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләрнең калганнарын тиешле бюджетка кайтару турында нигезләмә (күрсәтелгән субсидия финанс тәэмин итү чыганагы булган субсидия алучының акча йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелә торган субсидияләрдән кала), әгәр дә субсидияне тәкъдим итүче бюджет чараларын алучы тарафыннан әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый (хокукый) актлар белән билгеләнгән тәртиптә, агымдагы финанс елында субсидияләр бирү максатларына әлеге чараларны кулланууда ихтыяҗ булу турында карар кабул ителмәгән булса.

Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карар әлеге пункт белән күздә тотылган субсидияләр бирү тәртибе, субсидияләр бирү турында шартнамәләргә (килешүләргә) аларны бирүнең сроклары һәм шартлары турында таләпләрне дә кертеп Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органнары норматив хокукый актлары, Башкарма комитет муниципаль хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

8. Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан юридик затларга субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) төзү әлеге статьяның 1 һәм 8 пунктлары белән күздә тотылган, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр, концессион килешүләр турында бюджет йөкләмәләренең расланган эшчәнлек сроклары чикләреннән арткан, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органнары, Башкарма комитет карарлары нигезендә алар кабул итә һәм билгели торган тәртиптә тормышка ашырылалар.

2 бүлек. БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮ ҺӘМ РАСЛАУ

17 статья. Бюджет проектын төзү нигезләре

1. Бюджет проекты чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү максатларында социаль-икътисадый үсешне фаразлау нигезендә төзелә.

2. Җирле бюджет проекты муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан әлеге Кодекс һәм аның таләпләрен тотып кабул ителә торган муниципаль берәмлек Советы муниципаль хокукый актлары нигезендә төзелә.

Муниципаль берәмлек бюджеты проекты муниципаль берәмлек Советы муниципаль хокукый актлары нигезендә, әгәр дә Россия Федерациясе субъекты законы белән Татарстан Республикасы бюджеты турында законнан кала, муниципаль районнарның бюджет проектларын төзү һәм раслауга сроклар билгеләнмәгән булса, бер ел срокка (чираттагы финанс елга) яки өч ел срокка (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

Җирле бюджет проекты чираттагы финанс елына төзелгән һәм расланган очракта, башкарма комитет муниципаль берәмлекнең урта сроклы финанс планы эшләп чыгара һәм раслый.

18 статья. Бюджет проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр

1. Бюджет проектын вакытында һәм сыйфатлы итеп төзү максатларында финанс-бюджет палатасы башка финанс органнарыннан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кирәкле белешмәләр алырга хокуклы.

2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыенына юлламасындагы Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрне) билгели торган нигезләмәләренә;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләренә (Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә, муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә);

социаль-икътисадый үсеш фаразына;

озак сроклы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проектына, бюджет фаразына үзгәрешләр проектына);

дәүләт (муниципаль) программаларына (дәүләт (муниципаль) программалары проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына).;

19 статья. Социаль-икътисадый үсеш фаразы

1. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы кимендә өч ел чорга әзерләнә.

2. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы Башкарма комитет тарафыннан илгеләнгән тәртиптә ел саен әзерләнә.

3. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы Башкарма комитет тарафыннан хуплана һәм бюджет проектын закон чыгару (вәкиллекле) органга кертү турында карар кабул ителү белән бергә хуплана.

4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы план чорының параметрларын төгәлләштерү һәм план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән әзерләнә.

Социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуында фараз параметрларын нигезләү, шул исәптән, фаразлана торган үзгәрешләрнең сәбәпләрен һәм факторларын күрсәтеп, элек расланган параметрлар белән чагыштыру китерелә.

5. Бюджет проектын төзү яисә карау барышында муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразын үзгәртү бюджет проектының төп

характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

6. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразын төзү Башкарма комитетның вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) тарафыннан тормышка ашырыла.

7. Озак сроклы чорга Муниципаль берәмлекнең бюджет фаразын төзү максатларында РФ БКның 170.1 статьясы нигезендә Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә озак сроклы чорга муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы эшләнә.

20 статья. Район керемнәрен фаразлау

Район бюджеты керемнәре район үсешенең районның социаль-икътисади үсеше нигезендә район Советына бюджет туруында карар проекты кертелгән көнгә Россия Федерациясе бюджет законнары һәм салымнар һәм җыемнар турында законнар, шулай ук районның салымнан булмаган бюджет керемнәрен билгеләүче Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, мунициаль хокукый актлар шартлары нигезендә фаразлана.

Район керемнәре (чыгымнары) үзгәрүенә китерә торган, чираттагы финанс елына һәм планлы чорга район бюджеты турында карар проекты район Советына кертелгәннән соң кабул ителгән салымнар һәм җыемнар турында район Советы карарына үзгәрешләр кертүне күз алдында тоткан район Советы карары, күрсәтелгән район Советы карары чираттагы финанс елыннан соң килүче 1 нче гыйнвардан да алда кертелмәве турында нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш.

21 статья. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру

1. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру Финанс-бюджет палатасы билгели торган тәртиптә һәм методика буенча тормышка ашырыла.

2. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру бюджет ассигнованиеләре буенча аерым гамәлдәге һәм кабул ителәчәк йөкләмәләр нигезендә тормышка ашырыла.

3. Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр эшгәүгә) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру, киләсе финанс елына һәм планлы чорга күздә тотып, шулай ук аны үтәүне хисап финанс елына һәм агымдагы финанс елда тормышка ашырыла.

22 статья. Муниципаль программалар

1. Муниципаль программалар Башкарма комитет тарафыннан раслана.

Муниципаль программаларны гамәлгә ашыру сроклары Башкарма комитет урнаштыра торган тәртиптә аның тарафыннан билгеләнә.

Муниципаль программаларны эшләү турында карарлар кабул итү һәм күрсәтелгән программаларны булдыру һәм гамәлгә ашыру Башкарма комитетның муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме бюджет чыгымнарының һәрбер программага туры килә торган максатчан статьясы буенча, Башкарма комитетның программаны

раслаган муниципаль норматив хокукый акты нигезендә бюджет турында карар белән раслана.

Киләсе финанс елыннан башлап гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр Башкарма комитет билгеләгән срокларда расланырга тиеш.

Муниципаль программалар бюджеты турында законга (карарга) үз көченә кергән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча аңа туры китерелергә тиеш.

3. Һәр муниципаль программа буенча ел саен аны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә, әлеге бәяләүне үткәрү Тәртибе һәм аның критерийлары Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан элек кабул ителгән муниципаль программасын киләсе финанс елыннан башлап туктату яисә үзгәртү, шул исәптән муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү зарурлыгы турында карар кабул ителергә мөмкин.

23 статья. Муниципаль юл фонды

Муниципаль юл фонды Совет карары белән барлыкка килә.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) җирле бюджет турында карары белән муниципаль берәмлек Советы карары белән билгеләнгән, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемнәре фаразланган күләмнән дә кимрәк булмаган түбәндәге күләмдә раслана:

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына тиешле акцизлардан җирле бюджетка керемнәре;

җирлек бюджетына муниципаль берәмлек Советы карары белән билгеләнгән, муниципаль юл фондын барлыкка китерү өчен каралган башка төрле керемнәр.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен булдыру һәм куллану тәртибе Совет карары муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнә.

Муниципаль юл фондының агымдагы финанс елында кулланылмаган бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

24 статья. Бюджет турында карар проектында каралу һәм раслау өчен тәкъдим ителә торган күрсәткечләр составы

1. Бюджет турында Совет карарында бюджет турында төп характеристикалар, боларга бюджет керемнәре гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы (профициты), шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән башка күрсәткечләр керә.

Советның бюджет турында карарында җирлек бюджетлары арасында керемнәрнең бүленеше нормативлары булырга тиеш, әгәр дә алар Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан

Республикасы законы, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнмәсә.

2. Бюджет турында карар белән расланалар:

бюджет кереме баш администраторларының исемлеге;

бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясе чираттагы финанс елына чыгым төрләре буенча бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар, төркемнәргә (төркемнәр һәм төркемчәләр) бүлү яисә чыгым төрләре буенча бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар (дәүләт (муниципаль) программалар һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлеше), төркемнәргә (төркемнәр һәм төркемчәләр) бүлү һәм (яки) чыгым төрләре буенча (дәүләт (муниципаль) программалар һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлеше), төркемнәргә (төркемнәр һәм төркемчәләр), шулай ук РФ БК, Татарстан Республикасы законы, муниципаль берәмлек Советы муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү.

чираттагы финанс елына бюджет чыгымнары структурасының ведомство структурасы (чираттагы финанс елы һәм планлы чор);

ачык норматив йөкләмәләрне үтәү өчен җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

чираттагы финанс елында һәм планлы чорда башка бюджетлардан алына торган һәм (яки) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларга тәкъдим итә торган бюджетара трансфертлар күләме;

бюджетны киләсе финанс елына һәм планлы чорга раслау очрагында шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме планлы чорның беренче елына бюджет чыгымнарының гомуми күләменнән 2,5 процентта да ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларга тәкъдим итә торган бюджетара трансфертлар белән каралган максатчан юнәлешле бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), планлы чорның икенче елына бюджет чыгымнарының гомуми күләменнән 5 процентта да ким булмаган күләмдә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларга тәкъдим итә торган бюджетара трансфертлар белән каралган максатчан юнәлешле бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

чираттагы финанс елыннан соң килүче елның 1 нче гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге, планлы чорның һәр елы, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычларның югары чиген дә күрсәтеп;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән бюджетның башка күрсәткечләре.

3. Советның бюджет турында карары белән чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә кертергә (бюджетта чагылдырылырга) тәкъдим ителә торган салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре (ярдәмче төрләре) буенча бюджет керемнәрен бюджет турында карар белән расланган максатларга туры килүче бюджет

ассигнованиеләреннән һәм (яки) бюджет чыгымнарының гомуми күләмен артыграк файдалану күздә тотылырга мөмкин.

3 бүлек. БЮДЖЕТНЫ КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

25 статья. Бюджет турында карар проектын Совет каравына кертү

1. Башкарма комитет Совет белән билгеләнгән срокларда агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча бюджет турында карар проектын бер үк вакытта түбәндәге документлар һәм материаллар белән Совет каравына кертә:

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

агымдагы финанс елының узган чорына билгеле территориянең социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм агымдагы финанс елында билгеле территориянең социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары;

муниципаль берәмлек территориясенең социаль-икътисадый үсеш фаразы;

чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеле территориянең берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы (профицит) фаразы, яки расланган урта сроклы финанс план;

бюджет проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикаларның проектлары) һәм исәп-хисаплары;

муниципаль эчке бурычның чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына иң югары чиге (чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан);

агымдагы финанс елына бюджетның көтелә торган үтәлешен бәяләү;

район Советы, суд системасы органнары, эчке муниципаль финанс контроле тарафыннан тәкъдим ителгән бюджет сметаларына карата финанс органы белән каршылыклар килеп чыккан очракта тапшырыла торган күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары

бюджет керемнәре чыганаклары реестры;

башка документлар һәм материаллар.

Бюджет турында карар расланган очракта бюджет турында закон (карар) проектына бюджет ассигнованиеләрен дәүләт (муниципаль) программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бүлеп биргәндә дәүләт (муниципаль) программалар паспортлары (күрсәтелгән паспортларга үзгәреш проектлары) тәкъдим ителә.

Бюджет турында карар проекты бюджет классификацияләре буенча бюджет ассигнованиеләренең бүлекләр, бүлекчәләре буенча бүленешендә кушымта булмаган очракта, бюджет ассигнованиеләренең бүлекләр, бүлекчәләре буенча бүленешен үз эченә алган кушымта бюджет турында карар проектының аңлатма язуына кертелә.

26 статья. Бюджет турында карар проектын карау һәм аны раслау тәртибе

1. Чираттагы финанс елына бюджет турында карар проектын Советка керткәннән соң 3 көн дәвамында Башлык аны районның Контроль-хисап палатасына җибәрә.

2. Районның Контроль-хисап палатасы бюджет турында карар проекты турында әлеге проектның җитешсезлекләре ачыкланган очракта аларны күрсәтеп бер атна эчендә бәяләмә әзерли.

Районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе Совет депутатлары тарафыннан бюджет турында карар проектына үзгәрешләр керткәндә исәпкә алына.

3. Чираттагы финанс елына бюджет турында карар проекты районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән Советның даими комиссиясенә, шулай ук Совет депутатларына каралырга җибәрелә.

4. Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән бюджет турында карар проекты даими Совет комиссиясенә җибәрелгән моменттан бер атна эчендә муниципаль берәмлекнең бюджеты турында карар проектының беренче укылышы уздырыла.

Беренче укылышның предметы булып муниципаль берәмлекнең бюджеты турында карар проектының төп параметрларын хуплау тора.

Беренче укылышта кабул ителгән бюджет проекты алга таба гавами тыңлаулар уздыру максаты белән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылырга тиешле.

5. Гавами тыңлаулар процедурасы уздырылганнан соң 14 нче декабрьдән дә соңга калмыйча бюджет турында карар проекты Совет тарафыннан икенче укылышта карала.

Бюджет турында карар проекты икенче укылышта тәгаен кабул ителә.

6. Бюджет турында карар проекты буенча килешенмәгән мәсьәләләр килеп чыккан очракта, Башлык карары белән бер тигез санда Башкарма комитет һәм Совет вәкилләре кергән килештерү комиссиясе оештырылырга мөмкин.

Килештерү комиссиясе бюджет турында карар проектыныж беренче һәм икенче укылышлары арасындагы бәхәсле мәсьәләрне, Совет рәисе раслаган регламент нигезендә карый.

7. Совет тарафыннан чираттагы финанс елына кабул ителгән бюджет турында карар 5 эш көне дәвамында район Башлыгына имза куяр һәм бастырылып чыгарылыр өчен җибәрелә.

8. Бюджет турында Совет карары чираттагы финанс елының 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә.

9. Бюджет турында Совет карары агымдагы финанс елы башыннан үз көченә кергән булса, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджет белән вакытлыча идарә итү режимы кертелә.

4 бүлек. БЮДЖЕТНЫ ҮТӘҮ

27 статья. Бюджетны үтәү нигезләре

1. Бюджетны үтәү район Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә. Бюджетны үтәүне оештыру районның Финанс-бюджет палатасына йөкләнелә.

2. Бюджет касса бердәйлеге нигезендә һәм чыгымнарның кайсы ведомствога буйсынуына карап үтәлә.

28 статья. Җыелма бюджет язмасы һәм касса планы

1. Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибе районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

Җыелма бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү районның Финанс-бюджет палатасы рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җыелма бюджет язмасының расланган күрсәткечләре бюджет турында карарга туры килергә тиеш.

Бюджет турында законга (карарга) үзгәрешләр кертү хакында закон (карар) кабул ителгән очракта, районның Финанс-бюджет палатасы рәисе җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләрне раслый.

3. Җыелма бюджет язмасына, бюджет турында законга (карарга) үзгәрешләр кертмичә генә, финанс органы җитәкчесе (дәүләт бюджеттан тыш фонды белән идарә итүче орган җитәкчесе) карары нигезендә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен кабат бүлгән очракта – бу йөкләмәләрне агымдагы финанс елында үтәү өчен бюджет турында карар белән расланган әлеге бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә, шулай ук аны расланган бюджет ассигнованиеләре составындагы резерв акчаларны кабат бүлү исәбеннән 5 процент чикләрендә арттырып;

бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең), бюджет акчаларын алучыларның функцияләре һәм вәкаләтләре үзгәргән очракта, шулай ук дәүләт мөлкәтен тапшыруга, бюджет акчаларын бүлүчеләрнең (алучыларның) ведомство буйсынуын үзгәртүгә бәйле рәвештә һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан РФ БК 154 статьясындагы 5 пунктында каралган бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда;

бюджет акчаларыннан түләтүне күздә тота торган һәм (яисә) бу акчаларны суд чыгымнарын түләүгә, казна учреждениесе тарафыннан түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар суммасын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән социаль түләүләрне (гавами норматив йөкләмәләргә кергән түләүләрдән тыш) арттыруга күчерүне күздә тота торган суд актларын үтәгән очракта;

резерв фондлар акчаларыннан, шулай ук расланган бюджет ассигнованиеләре составында башка рәвештә резервланган акчалардан файдаланган (яңадан бүлгән) очракта, бюджеты турында карарда алардан файдалану күләмнәрен һәм юнәлешләрен күрсәтеп;

конкурс нигезендә бирелгән бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлгән очракта;

бюджет ассигнованиеләрен агымдагы финанс елы һәм план чоры арасында яңадан бүлгән очракта – тиешле финанс елына муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен бюджет акчаларын баш бүлүчегә бюджет турында законда (карарда) каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә;

бюджет турында карарда расланган күләмнәрдән тыш максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү турында хәбәрнамә алынган, физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган керемнәрне алган очракта, шулай ук күрсәтелгән бюджетара трансфертларны кыскарткан (ихтыяҗ булмаганда кире кайтарган) очракта;

муниципаль учреждениеләренең (ведомство буйсынуы) төре һәм муниципаль унитар предприятиеләренең оештыру-хокукый рәвеше үзгәргән очракта;

товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль дәүләт (муниципаль) контрактлары шартлары нигезендә финанс хисабы елында түләнергә тиешле әлеге муниципаль контрактларын түләү өчен агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләрен әлеге муниципаль контрактларны үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә РФ БК белән билгеләнгән таләпләргә таянып арттырган очракта;

бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга һәм муниципаль милек объектларына капитал салуларны башкару өчен субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен (юл фондының бюджет ассигнованиеләреннән тыш), РФ БКның 78.2 статьясындагы 2 пунктында һәм 70 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән карарларга, капитал салуларны башкаруга субсидияләр бирү турында муниципаль контрактларына йә килешүләргә үзгәрешләр кертелгәннән соң, муниципаль милектә күрсәтелгән объектка капитал салулар башкаруны финанс белән тәэмин итү ысулын үзгәрткәндә.

Җирле бюджетның әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән акчалары районның Финанс-бюджет палатасына карала, яисә әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән очракларда әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән акчалардан файдалану тәртибе (файдалану турында, кабат бүлү турында карарлар кабул итү тәртибе) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

Җыелма бюджет язмасына әлеге пунктта билгеләнгән нигезләрдә үзгәрешләр кертү бюджет турында карар белән расланган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә башкарыла, моңа җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертүне бюджет турында карар белән расланган чыгымнарның гомуми күләмен арттырып гамәлгә ашыру мөмкинлеген урнаштыра торган әлеге пунктның сигезенче һәм унынчы абзацларында билгеләнгән нигезләр керми.

Җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр керткәндә гавами норматив йөкләмәләрне үтәү һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен бюджет турында карарга үзгәрешләр кертмичә генә башка бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен киметү рөхсәт ителми.

4. Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә җыелма бюджет язмасы күрсәткечләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджет чараларын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча раслау каралырга тиеш.

Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджетлар чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, төркемчәләре (төркемнәре, төркемчәләре һәм элементлары), шул исәптән бюджетның төрле максатчан статьялары һәм (яисә) чыгымнар төрләре өчен, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр өчен дифференциацияле раслау каралырга мөмкин.

5. Җыелма бюджет язмасының чыгымнар буенча расланган күрсәткечләре, РФ

БКның 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башланганчы бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә җиткерелә.

Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр, шул исәптән әлеге статьяда күрсәтелгән нигезләрнең төрле төрләре буенча дифференциацияләнгән рәвештә, кертүнең иң чик вакытлары билгеләнергә мөмкин.

6. Җыелма бюджет язмасына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре кертелә, моңа бюджетның бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр керми.

7. Бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль берәмлек Советы муниципаль хокукый актлары нигезендә (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фонд бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм "Чираттагы финанс елына бюджет турында" муниципаль берәмлек Советы карарыннан кала) җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү турында бюджет турында карарга үзгәрешләр кертми генә, финанс органы җитәкчесе (дәүләт бюджеттан тыш фонды белән идарә итүче орган җитәкчесе) карарлары нигезендә өстәмә нигезләр кертелергә һәм (яки) күрсәтелгән өстәмә нигезләрне бюджет турында карарга кертү нигезләмәләре күздә тотылырга мөмкин.

8. Касса планы дигәндә, бюджетка касса керемнәренең һәм агымдагы финанс елында бюджеттан касса түләүләренең фаразы дип аңларга кирәк.

Касса планында бюджетның бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләрне гамәлгә ашыруга тотыла торган акча чараларының иң чик күләме билгеләнә.

Муниципаль контрактларны, башка шартнамәләрне түләү буенча бюджеттан касса түләүләре фаразы, төзелә торган муниципаль контрактлар, башка шартнамәләр буенча акча йөкләмәләрен түләүнең дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны планлаштырганда билгеләнгән срокларын һәм күләмнәрен исәпкә алып ясала.

Касса планын төзү һәм алып бару районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

29 статья. Бюджетны керемнәр буенча үтәү

Бюджет керемнәр буенча үтәү түбәндәгеләрне күздә тота:

бюджетның бердәй счетына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджетка салымнарны, җыемнарны һәм башка керемнәрне бүлүдән алынучы керемнәрне күчерү;

артык бүленгән суммаларны күчерү, артык түләнгән яисә артык алынган суммаларны кире кайтару, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар суммаларын кире кайтару;

Россия Федерациясе законнары нигезендә артык түләнгән яисә артык алынган суммаларны исәпкә алу;

бюджетка түләүләрне бюджет керемнәренең администраторы тарафыннан төгәлләштерү;

артык бүленгән суммаларны, артык түләнгән яисә артык алынган салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтаруны (исәпкә алуны, ачыклауны), шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар суммаларын кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчаларны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджетның бердәй счетыннан Федераль казначылык тарафыннан күчерү.

30 статья. Бюджетны чыгымнар буенча үтәү

1. Бюджетның чыгымнар буенча үтәлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Нигезләмә таләпләрен истә тотып, Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Бюджетның чыгымнар буенча үтәлеше дигәндә түбәндәгеләр күздә тотыла:

бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү һәм аларның исәбен алып бару;

акчалата йөкләмәләрне раслау;

акчалата йөкләмәләрне түләүне санкциялә;

акчалата йөкләмәләрне үтәүне раслау.

3. Бюджет чараларын алучы бюджет йөкләмәләрен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәле лимитлары чикләрендә кабул итә.

Бюджет чараларын алучы бюджет йөкләмәләрен дәүләт (муниципаль) контрактлар, физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән башка төр килешүләр төзү юлы белән яисә закон, башка хокукый акт, килешү нигезендә кабул итә.

4. Бюджет чараларын алучы түләргә тиеш булу йөкләмәсен бюджет чаралары хисабына, аларны түләү өчен санкцияләнүгә кирәкле акча йөкләмәләре буенча раслый, ә оператив-эзләү чараларын үтәү һәм зыян күрүчеләр, шаһитләр һәм башка төр җинаять суд эше белән бәйле катнашучылар белән бәйле булган очракларда, түләү документлраы нигезендә.

5. Акча йөкләмәләрен түләүне санкцияләү рөхсәт бирүче язма (акцепт) уздырылу формасында, финанс органы белән белән билгеләнгән тәртиптә (дәүләт бюджеттан тыш фондының идарә органы) акча йөкләмәләрен санкцияләнелгән түләүдә каралган тәртиптә документлар булуын тикшергәннән соң, әлеге Кодекс нигезләмәләре нигезендә тормышка ашырыла.

Дәүләт (муниципаль) контрактлар буенча акча йөкләмәләрен санкцияләнелгән түләү өчен өстәмәмә рәвештә дәүләт (муниципаль) контракт буенча мәгълүматларның дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр өлкәсендә Россия Федерациясе контракт системасы турында законнары нигезендә контрактлар реестрында дөреслеген тикшерү һәм дәүләт (муниципаль) контракт буенча әлеге дәүләт (муниципаль) контракт шартлары буенча исәпкә алынган бюджет йөкләмәләре турында мәгълүматлар исәпкә алу тормышка ашырыла.

Акча йөкләмәләрен түләү (гавами норматив йөкләмәләр буенча акча йөкләмәләреннән кала) бюджет чараларын алучы бюджет йөкләмәләрен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәле лимитлары чикләрендә тормышка ашырыла.

Гавами норматив йөкләмәләр буенча акча йөкләмәләрен түләү бюджет

чараларын алучыга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тормышка ашырылырга мөмкин.

6. Акча йөкләмәләрен үтүне раслау бердәм бюджет исәбеннән чыгарылган акчаларны раслаучы түләү документлары нигезендә физик яки юридик затлар файдасына, Россия Федерациясе бюджет системасы, халыкара хокук субъекты, шулай ук бюджет чараларын алучыларның акча белән булмаган башка операцияләр уздыруын раслаучы башка төр документларны тикшерү нигезендә тормышка ашырыла.

31 статья. Бюджет язмасы

1. Бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең) бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе, аларга үзгәрешләр кертүне дә кертеп, районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

Бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең бюджет язмалары җыелма бюджет язмасы белән расланган бюджет ассигнованиеләре һәм Финанс-бюджет палатасы тарафыннан расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

Бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең бюджет язмалары бюджет ассигнованиеләре һәм аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

2. Бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Чыгымнар һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, РФ БКның 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башланганчы бюджет акчаларын ведомство бүлүчеләренә һәм (яики) акчаларын алучыларга җиткерелә.

3. Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) раслана торган бюджет йөкләмәләре лимитларын чыгымнар төрләре төркемчәләре (төркемчәләре һәм элементлары) буенча детальләштерүне гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә хокуклы.

4. Бюджетның җыелма бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчаларын баш бүлүченең чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне бюджетның җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

Бюджетның җыелма бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә бюджет акчаларын бүлүченең чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

32 статья. Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше

1. Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше, моңа бюджетның бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр керми, районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бюджетның җыелма бюджет язмасы нигезендә бюджет кытлыгын финанслау

чыганакларының баш администраторлары, администраторлары тарафыннан гамәлгә ашарыла.

Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү районның Финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

33 статья. Бюджет сметасы

1. Казна учреждениесенең бюджет сметасы үз карамагында казна учреждениесе булган бюджет акчаларын баш бүлүче билгели торган тәртиптә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә төзелә, раслана һәм алып барыла.

Бюджет акчаларын баш бүлүче буларак бюджет вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә органы булган казна учреждениесенең бюджет сметасы әлеге органның җитәкчесе тарафыннан раслана.

2. Казна учреждениесенең расланган бюджет сметасы күрсәткечләре казна учреждениесе функцияләрен үтәүне тәэмин итү буенча бюджет йөкләмәләрен кабул итү һәм (яки) үтәү өчен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларына туры килергә тиеш.

Казна учреждениесенең бюджет сметасында казна учреждениесенең бюджет сметасын төзү һәм алып бару тәртибендә каралган башка өстәмә күрсәткечләр дә расланырга тиеш.

Казна учреждениесенең бюджет сметасын раслау тәртибе нигезендә җитәкчесенә аны раслау хокукы бирелгән казна учреждениесенең бюджет сметасы күрсәткечләре дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары буенча җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, шулай ук тиешле төркемнәренең (статьяларының) статьялары (өстәмә статьялары) кодлары буенча өстәмә рәвештә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре чикләрендә детальләштерелергә мөмкин.

34 статья. Финанслауның иң чик күләмнәре

1. Бюджетны чыгымнар буенча үтәүне оештырганда районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә бюджет акчаларын агымдагы финанс елының тиешле чорында акчалата йөкләмәләрне түләүнең иң чик күләмен (финанслауның иң чик күләмнәрен) раслау һәм аларны акчаларны баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга җиткерү каралырга мөмкин.

2. Финанслауның иң чик күләмнәре бюджет акчаларын баш бүлүчегә, бүлүчегә һәм алучыга карата тулаем ай саен яисә квартал саен йә агымдагы финанс елы башыннан арта бара торган нәтиҗә белән йә бюджет акчаларын баш бүлүчеләрне, бүлүчеләрне һәм алучыларны финанслауга заявкалар нигезендә тиешле кварталга билгеләнә.

35 статья. Бюджетны үтәгәндә бюджет турында карар белән расланганнан тыш фактта артыграк алынган керемнәрдән файдалану

1. Бюджетны үтәгәндә бюджет турында карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән фактта артыграк алынган керемнәр, агымдагы финанас елына

(агымдагы финанс елына һәм планлы чорга) бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә генә, финанс органы тарафыннан үзара муниципаль исәпләшүләрен урнаштыруга, муниципаль бурычны каплауга, шулай ук субъектның гавами норматив йөкләмәләрен үтәүгә әлеге Нигезләмәнең 28 статьясындагы 3 бүлеге 1 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта аларны үтәү өчен җибәрелергә мөмкин.

2. Бюджетны үтәгәндә бюджет турында закон (карар) белән расланган керемнәрдән тыш фактта артыграк алынган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар (аларны бирү турында хәбәрнамә алынган очракта), шул исәптән бюджетка РФ БКның 242 статьясы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә керә торганнары, шулай ук физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган керемнәр, агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында законга (карарга) үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында тиешенчә бюджет чыгымнарын арттыруга җибәрелә.

36 статья. Агымдагы финанс елын тәмамлау

1. Бюджетны үтәү буенча операцияләр 31 декабрьдә тәмамлана, моңа РФ БКның 242 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән операцияләр керми.

Агымдагы финанс елында бюджетны үтәү буенча операцияләрне тәмамлау районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге статья таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләре, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм финанслауның иң чик күләмнәре 31 декабрьдә үзләренең гамәлдә булуларын туктаталар.

Агымдагы финанс елының соңгы эш көненә кадәр бюджетны үтәүгә касса хезмәте күрсәтүче орган бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар чикләрендә санкцияләнгән бюджет йөкләмәләрен билгеләнгән тәртиптә түләргә тиеш.

3. Бюджет акчаларын алучылар тарафыннан бердәм бюджет счетында кулланылмый калган бюджет акчалары агымдагы финанс елының соңгы ике эш көненән дә соңга калмыйча бюджет акчаларын алучылар тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш.

4. Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар бюджет керемене агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет), бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджеты акчалары баш администраторының, финанс органы, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә аның белән килештерелгән, финанс хисабы елында файдаланылмый калган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм, финанс белән тәэмин итү чыганагы

Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калган акчаларыннан артык булмаган күләмдәге акчалар бюджетның әлеге бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында үзләре элек бирелгән бюджет керемене кире кайтарылырга мөмкин.

Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган бюджетара трансфертлардан тыш, һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган һәм кулланылмыйча калган бюджетара трансфертлар билгеле бюджет керемене күчерелмәгән очракта бу акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәгән килеш, билгеле финанс органы, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә алар бирелгән бюджет керемене алынырга тиеш.

5. Районның финанс-бюджет палатасы агымдагы финанс елы тәмамланганда бюджет акчаларын алучыларны чираттагы финанс елының гыйнварында Россия Федерациясендә эш булмаган бәйрәм көннәрендә аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар белән тәэмин итү тәртибен билгели.

5 бүлек. БЮДЖЕТ ХИСАБЫН ТӨЗҮ, ТЫШКЫ ТИКШЕРҮ, КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

37 статья. Бюджет исәбе һәм бюджет хисаплыгы нигезләре

1. Бюджет исәбе һәм бюджет хисаплылыгы нигезләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

2. Бюджет хисаплылыгына түбәндәгеләр керә:

1) бюджет үтәлеше турында хисап;

2) бюджет үтәлеше балансы;

3) эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;

4) акчалар йөреше турында хисап;

5) аңлатма язуы.

3. Бюджет хисаплылыгы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә тиешенчә районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан төзелә.

4. Бюджет хисаплылыгы еллык хисап була. Бюджет үтәлеше турындагы хисап квартал саен була.

5. Бюджет хисаплылыгы районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан тиешенчә Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырыла.

6. Агымдагы финанс елының беренче кварталында, ярты еллыгында һәм тугыз аенда бюджет үтәлеше турындагы хисап Башкарма комитет тарафыннан раслана һәм

тиешенчә Советка һәм районның Контроль-хисап палатасына җибәрелә.

38 статья. Бюджет үтәлеше турында еллык хисап

1. Бюджет үтәлеше турында еллык хисап Советта каралганчыга кадәр, бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплыгы турында тышкы тикшерене үз эченә алган тышкы тикшерү узарга һәм бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләнергә тиешле.

2. Бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерүне районның Контроль-хисап палатасы тормышка ашыра.

3. Башкарма комитет ел саен агымдагы елның 1 нче апреленнән дә соңга калмыйча бюджет үтәлеше турындагы хисапны аңа бәяләмә әзерләү өчен тапшыра.

Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бергә бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бергә Советка бирелергә тиешле карар проекты һәм башка документлар тәкъдим ителә. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер ай сроктан да артык булмаган вакыт аралыгында уздырыла.

4. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан Советка җибәрү белән бер үк вакытта Башкарма комитетка да җибәрелә.

5. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап Советка агымдагы елның 1 нче маеннан да соңга калмыйча җибәрелә.

Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бергә бюджет үтәлеше турындагы муниципаль берәмлек Советы карар проекты, башка бюджет үтәлеше турындагы бюджет хисаплаштыруы һәм берләштерелгән бюджет үтәлеше турындагы бюджет хисаплаштыруы, һәм Россия Федерациясе бюджет законнары белән каралган башка документлар да тәкъдим ителә.

6. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча Совет бюджет үтәлеше турында карарны раслау яисә кире кагу турында карар кабел итә.

Совет тарафыннан бюджет үтәлеше турындагы карар дөрес булмаган яисә тулы чагылдырылмаган белешмәләр булуы ачыкланган очракта бер ай сроктан да артмаган вакытка кабаттан тәкъдим ителү өчен кире кайтарыла.

7. Бюджет үтәлеше турында Совет карары белән хисап финанс елына бюджет үтәлеше турындагы хисап бюджет керемнәренең, чыгымнарының һәм кытлыгының (профицит) гомуми суммасы күрсәтелеп раслана. Бюджеты үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча бюджет керемнәре;
- бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча бюджет чыгымнары;
- бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджеты чыгымнары;
- бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары.

39 статья. Муниципаль финанас контрольне тормышка ашыручы

органнар

1. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле районның Контроль-хисап органнарының контрольлек итү эшчәнлеге булып тора.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле районның Финанс-бюджет палатасының контрольлек итү эшчәнлеге булып тора.

3. Муниципаль финанс контроле органнарының бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясенең Бюджет кодексы нигезендә билгеләнә.